# Мәйдан

№ 08

әдәби-нәфис, иҗтимагый журнал

август / 2024

## Өр-яңа авторның тәүге романы

Айдар НУРИЕВ, 5 бит

## Тормышта иң зур хатам – Казаннан китү

Әнвәр ШӘРИПОВ, 91 бит

## Татарга татар атларын кайтарасым килде

Ризидә ГАСЫЙМОВА, 128 бит



podpiska.pochta.ru






# Миләүшә Айтуганова:

## *«Әлек татарның киносы юк, диләр иде, хәзер ул бар»*

Татарстанда төшерелгән кино... Татарча кино... Бу хакта сүз башлыйбыз икән, «Татаркино» берләшмәсе җитәкчесе Миләүшә Айтуганова исемен телгә алмый калып булмыйдыр. Татар телендә төшерелеп, экраннарга чыккан егермедән артык фильмга йә продюсер, йә сценарий авторы буларак зур өлеш керткән шәхес ул. Иң популярларын гына санасак та – «Язмышлардан узмыш юк», «Яланаяклы кыз», «Ерактагы йолдызым», «Уеннан уймак», «Ак чәчәкләр», «Тапшырылмаган хатлар», «Хәлимә», «Мулла», «Остазбикә», «Әпипә», «Сөмбел», «Без – 41нче ел балалары», «823 километр»... Шулар өстенә ул әле Татарстанда кино сәнгате үсешенә зур йогынты ясаган Казан Халыкара «Алтын мөнбәр» мөселман кинофестиваленең башкарма директоры да. Һәм өстәвенә әле Казан дәүләт мәдәният институты профессоры.

Үсеш дигәннән, соңгы елларда татарда кино сәнгате, чыннан да, күрми калып булмаслык күтәрелеш кичерә кебек. «Татаркино» берләшмәсе белән беррәттән, Илшат Рәхимбай, Байбулат Батулла, Алмаз Нургалиев кебек аерым эшләүче яшь режиссерларның килеп чыгуы һәм бүген татарча фильмнарның татар җәмәгатьчелегенә генә түгел, хәтта зуррак аудиториягә дә тәкъдим ителә башлавы – моңа ачык мисал. Әмма бу үсеш-үзгәрешләр эзлекле күренешме икән? Татар киноиндустриясенә бүген нинди проблемалар хас? Миләүшә ханым белән без шул хакта сөйләшеп утырдык.

podpiska.pochta.ru



Гөлназ ГАФАРОВА

# Җиңү

Почта әрҗәсеннән гәзитләрне алу белән, Алсу битенә терәде. Их, искәе соң, искәе! Элеккедән бераз кайтышрак булса да, тәмле-е-е! Өйгә кереп диванга артын терәгәч тә бертын иснәп утырды әле. Чир китә, гадәт китми дигәннәре шушы буладыр, күрәсең. Яңа гәзит-журнал, кием, акча иснәү Алсуда бәләкәй чактан ук. «Ярамый, агу бит ул!» – дип, һәрчак кисәтеп торды апалары. Алсу, әбисе әйтмешли, арт ягына да элмәде, үзенекен эшли торды. Ә гәзит-журналны аларның гаиләсе күпләп алдырды. Ике тугандаш республика – Татарстан, Башкортстан басмаларын гына түгел, илебез башкаласы чыгарганнарына да язылдылар. Әниләренең укытучы булуы сәбәп идеме моңа, әллә барсының да укуга мәхәббәте көчле булдымы, белмәссең. Хат ташучы Лена апа, почта әрҗәсенә сыймагач, капкага кыстыра, я өйгә үк кертеп бирә торган иде аларны. Хаклары да хәзерге кебек тешләмәгәндер, мөгаен. Югыйсә, сигез кешедән торган гаиләнең ундүрт-унбиш төрле гәзит-журналга язылырга көче җитмәс иде.

Почта килгән көн – гаиләдә бәйрәм! Лена апаларның өйләре Алсуларның бәләкәй як тәрәзәсеннән күренеп тора. Алар турына зәңгәр фургонлы машина килеп туктаганны күрсәләр, әй шатлана торган иде Алсулар. Аннары Лена апаның кайчан гәзит таратырга чыгуын дүрт күзләп көтә башлыйлар. Күреп калдылар исә, каршысына йөгереп чыгалар. Барысының да яңа табадан төшкән басмаларны беренче булып кулларына аласы килә. Өстәвенә эчендә хат та булса!

Берчак шулай Алсуның ике апасы, кем узардан гәзит алырга чапканда, чак кына башларын ярмый калдылар. Әлфинә апасы өч басасы күтәрмә баскычына ике генә баскан иде, маңгае белән ишек яңагына килеп бәрел-

podpiska.pochta.ru